КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 18 ноябрь г.Казань № 1018

2024 елда дәүләт (муниципаль) учреждениесе булмаган юридик затка «Физик-математик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, гомуми таләпләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә һәм сайлап алуны уздыруга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2024 елда дәүләт (муниципаль) учреждениесе булмаган юридик затка «Физик-математик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 18 ноябрь, 1218 нче
карары белән расланды

2024 елда дәүләт (муниципаль) учреждениесе булмаган юридик затка «Физик-математик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2024 елда дәүләт (муниципаль) учреждениесе булмаган юридик затка Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Белем бирү сыйфатын үстерү» процесслы чаралар комплексында каралган «Физик-математик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба тиешенчә - субсидия, юридик зат) бирү максатларын, шартларын һәм механизмын билгели.

2. Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет акчаларын алучы буларак, 2024 елда субсидия алуга бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын төп бүлүче булып Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба - Министрлык) тора.

3. Әлеге Тәртиптә «Физик-математик алгарыш» проекты дигәндә физика-математика белеме бирүнең сыйфатын күтәрүгә, балаларның математик сәләтләрен үстерүгә, физика-математик белем бирүне популярлаштыруга һәм математика һәм физика укытучыларына методик ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы аңлашыла.

4. Субсидия бирү максаты булып «Физик-математик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле юридик затның чыгымнарын финанс белән тәэмин итү тора.

5. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

6. Сайлап алуны үткәрү ысуллары - юридик затлар тарафыннан сайлап алуда катнашу өчен җибәрелгән заявкалар нигезендә (алга таба - заявка) юридик затның әлеге Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкалар керүнең чиратлылыгыннан чыгып, тәкъдимнәрне сорату.

7. Юридик затны сайлап алу критерийлары:

физика, математика фәннәрен өйрәнүне популярлаштыруга юнәлдерелгән төрле дәрәҗәдәге чараларны оештыру һәм үткәрү, заявка биргән датага торышы буенча кимендә өч ел физика, математика өлкәсендәге эшчәнлекне алып бару;

укытуны гамәлгә ашыручы оешмаларга, табигый-фәнни цикл предметларын укытучы педагогик хезмәткәрләргә физика, математика өлкәсендә заманча фәнни, технологик казанышларны куллану, файдалану, укыту мәсьәләләре буенча мәгълүмати-методик, ресурс ярдәме күрсәтү;

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

гомуми белем бирү һәм (яисә) балаларга өстәмә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия булу.

8. Заявканы карау һәм субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү даталарына торышы буенча юридик зат түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

юридик затның бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычы булмау яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

юридик затның башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмау (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчеләр, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яки юридик затның баш хисапчысы турында мәгълүматлар булмау;

юридик зат үзгәртеп оештыру (юридик затка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәү, юридик затның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмау;

юридик зат чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннанраслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

юридик зат экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

юридик зат БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә түгел;

юридик зат «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

юриди зат әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый.

9. Юридик зат сайлап алуда катнашу өчен Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

юридик зат турында, шулай ук килешүне имзалауга вәкаләтле зат турында, субсидия бирүнең сайлап алуга һәм нәтиҗәсенә бәйле юридик зат турында башка мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыкны үз эченә алган заявка (тулы һәм кыскартылган исеме, төп дәүләт теркәве номеры, салым түләүченең идентификация номеры, дәүләт теркәве датасы, адресы, элемтә телефоны номеры, почта адресы һәм электрон почта адресы, юридик әһәмиятле хәбәрләрне җибәрү өчен, җитәкче турында мәгълүмат, субсидияне күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә счетлар турында мәгълүмат) әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә форма буенча юридик зат тарафыннан тапшырыла торган заявка;

юридик затның гамәлгә кую документларының, шулай ук аларга карата булган барлык үзгәрешләр турында документларның юридик зат җитәкчесе яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле башка зат тарафыннан таныкланган күчермәләре;

юридик затның әлеге Тәртипнең 8 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган, юридик зат җитәкчесе яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган гарантияле хат;

юридик зат тарафыннан физика, математика фәннәрен өйрәнүне популярлаштыруга юнәлдерелгән төрле дәрәҗәдәге чараларны оештыру һәм үткәрүне, заявка биргән датага торышы буенча кимендә өч ел физика, математика өлкәсендәге эшчәнлекне алып баруны раслый торган документлар;

юридик зат тарафыннан укытуны гамәлгә ашыручы оешмаларга, табигый-фәнни цикл предметларын укытучы педагогик хезмәткәрләргә физика, математика өлкәсендә заманча фәнни, технологик казанышларны куллану, файдалану, укыту мәсьәләләре буенча мәгълүмати-методик, ресурс ярдәме күрсәтүне раслый торган документлар;

финанс белән тәэмин итү чыганагы әлеге Тәртипнең 25 пунктында күрсәтелгән субсидия булган чыгымнар юнәлешләре нигезендә әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән максатка, юридик зат җитәкчесе яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтле зат тарафыннан расланган чыгымнар сметасы;

бердәм салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы булмау яисә

Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмауны раслый торган салым органы белешмәсе;

үз эченә түбәндәге мәҗбүри чараларны алган «Физик-математик алгарыш» проекты чаралары планы:

укучылар, укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре), «физика», «математика» предметлары буенча педагогик хезмәткәрләр өчен төрле дәрәҗәдәге мәгариф һәм башка чаралар үткәрү (муниципаль дәрәҗәдә, төбәк дәрәҗәсендә укытуны гамәлгә ашыручы оешмада) ;

хезмәттәшлек турында төзелгән килешүләр нигезендә «Физик-математик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында аерым предметларны һәм (яисә) һөнәри юнәлеш чараларын (пилот физика-математика классларын) тирәнтен өйрәнү буенча белем бирү программаларын гамәлгә ашыру буенча гомуми белем бирү оешмалары белән үзара хезмәттәшлекне оештыру;

«физика», «математика» предметлары буенча укытуны гамәлгә ашыручы педагогик хезмәткәрләргә һәм (яисә) оешмаларга мәгълүмати-методик ярдәм күрсәтү;

«физика», «математика» предметлары буенча укучыларга ярдәм күрсәтү яисә алар белән индивидуаль эш башкару;

Татарстан Республикасы территориясендә мәгариф оешмаларында укучыла арасында диагностик чаралар үткәрү;

«Физик-математик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру буенча башка чаралар.

Әлеге пунктның сигезенче абзацында күрсәтелгән документ юридик зат тарафыннан тәкъдим ителмәгән очракта, Министрлык аны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

10. Юридик зат сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән срокларда кәгазьдә юридик зат яки юридик зат исеменнән эш итәргә вәкаләтле зат тарафыннан үз кулы белән имзаланган заявка төзи һәм бирә. Заявка Министрлыкка турыдан-туры яки почта юлламасы белән җибәрелә. Заявка, шулай ук, сайлап алуны үткәрү турында игълан итүдә күрсәтелгән электрон почта адресына заявканың һәм документларның сканлаштырылган күчермәләре рәвешендә электрон рәвештә җибәрелергә мөмкин.

Һәр документ төгәл итеп басылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр (юридик зат җитәкчесенең үз имзасы белән расланган төзәтмәләрдән тыш) рөхсәт ителми.

Юридик зат тарафыннан заявка бирү датасы дип Министрлык урнашкан урын буенча почта бүлегенә почта юлламасы яисә турыдан-туры Министрлыкка керү датасы санала.

Юридик зат тарафыннан электрон рәвештә заявка бирү датасы - Министрлыкның электрон адресына сайлап алуны уздыру турында игълан итүдә күрсәтелгән заявка керү датасы.

11. Заявкага кертелә торган документларның һәм материалларның электрон күчермәләре барлык документны йә аның өлешен карау мәгълүматны карауны һәркем файдалана алырлык программа белән тәэмин итү чаралары белән карау мөмкинлеген тәэмин итә торган киң таралган ачык форматларга ия булырга тиеш һәм махсус программа яисә технологик чаралардан башка аларның эчтәлеге белән танышуны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланган яисә сакланган булырга тиеш түгел.

12. Юридик зат заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Кирәк булганда юридик зат заявкалар бирү өчен билгеләнгән вакыт эчендә кабат заявка бирергә хокуклы.

Заявкага үзгәрешләр кертү яисә заявканы кире алу юридик зат тарафыннан әлеге Тәртиптә билгеләнгән заявканы төзүнең шундый ук тәртибендә юридик зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Юридик зат тәкъдим ителгән заявкаларда һәм документларда булган мәгълүматның дөреслеге өчен җаваплы.

13. Министрлык заявкалар бирә башлау датасына кадәр биш календарь көннән дә соңга калмыйча кәгазьдә мөһер сугып һәм Министрлык җитәкчесе яисә вәкаләтле зат тарафыннан сайлап алуны үткәрү турында игълан итеп кул куйган килеш, аны сканерлый һәм аны бердәм порталда һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасын, шул ук вакытта заявкаларны кабул итеп алу тәмамлану датасы сайлап алу үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннең иртәгесеннән 10 календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 26 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

әлеге Тәртипнең 8 пункты нигезендә юридик затларга карата һәм әлеге Тәртипнең 9 пунктында каралган таләпләргә туры килүен раслау өчен юридик затлар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлегенә карата таләпләр;

юридик затны сайлап алу критерийларын;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны эшләп бетерүгә кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 19 –23 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

заявкаларны кире кагу тәртибе, шулай ук әлеге Тәртипнең 21 пункты нигезендә аларны кире кагу нигезләре турында мәгълүмат;

сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидия күләме, субсидия күләмен исәпләү тәртибе, сайлап алуда җиңүчегә бирелә торган субсидиянең максималь, минималь күләмен үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре буенча субсидияне бүлү кагыйдәләре, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны;

юридик затларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәгәлләнү датасын;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан килешүгә имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуны үткәрүне туктату тәртибе һәм очраклары, сайлап алу йомгаклары буенча килешүләр төзү очраклары һәм сайлап алу үткәрелмәгән дип тану очраклары;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсен урнаштыру сроклары (ул сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак була алмый).

14. Министрлык, табигый яисә техноген һәлакәтләр, хәрби хәрәкәтләр, Министрлык тарафыннан гадәттән тыш дип танылган башка хәлләр белән бәйле рәвештә барлыкка килгән, җиңеп булмый торган вакыйгалар килеп чыккан очракта, сайлап алу уздырмый.

Министрлык тарафыннан бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуны уздырмау турында белдерүне урнаштыру заявкалар бирү срогы тәмамланган датага кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә.

15. Сайлап алуны уздырмау турында белдерүгә Министрлык җитәкчесе тарафыннан кул куела, бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла һәм сайлап алуны уздырмау сәбәпләре турында мәгълүмат бирелә.

16. Сайлап алу аны гамәлдән чыгару турындагы игълан бердәм порталда урнаштырылган көннән сайлап алу гамәлдән чыгарылган дип санала.

Әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә сайлап алуны туктату срогы тәмамланганнан соң һәм сайлап алуның җиңүчесе белән килешү төзелгәнче Министрлык Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә җиңеп булмый торган көч шартлары барлыкка килгән очракта гына сайлап алуны юкка чыгарырга мөмкин.

17. Министрлыкка кергән заявка керү датасына һәм вакытына карап чират буенча кергән көннән алып бер эш көне эчендә теркәлә. Заявка биргән юридик затның вәкаләтле вәкиленә, аны алу датасын һәм вакытын күрсәтеп, Министрлыкның заявка алган вазыйфаи заты имзасы белән заявка алуда расписка бирелә.

Заявка почта элемтәсен оештыру аша кергәндә, заявканы теркәү датасы дип Министрлыкка почта җибәрүләрен турыдан-туры бирү белән шөгыльләнүче почта элемтәсен оештыруның структур бүлекчәсе тарафыннан почта аша җибәрү датасы һәм вакыты санала, һәм алар почта юлламасында почта элемтәсен оештыруның тиешле структур бүлекчәсе штемпеле белән расланган.

Заявка электрон формада кергәндә заявканы теркәүгә алу датасы итеп юридик заттан Министрлыкка кергән документка тәртип буенча керү саны бирелгән дата алына.

18. Бер юридик зат бер генә заявка бирергә мөмкин.

Әгәр сайлап алуда катнашуга бер заявка да тапшырылмаган булса, сайлап алу уздырылмаган дип таныла.

19. Заявкаларны карау заявкаларны карау комиссиясе (алга таба - комиссия) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Комиссия заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көннән соң килә торган көннән биш календарь көн эчендә:

заявкаларны һәм аларга кушымта итеп бирелгән документларны керү чираты нигезендә юридик затның һәм тәкъдим ителгән заявканың әлеге Тәртипнең 7 һәм

8 пунктларында һәм сайлап алуны үткәрү турында игъланда каралган таләпләргә һәм критерийларга туры килү предметына карый;

сайлап алуда җиңүчене билгеләү турында карар кабул итә, ул комиссия утырышы үткәрелгән көндә комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә һәм комиссия рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана.

Әгәр утырышта комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, комиссия утырышы тулы хокуклы дип санала.

Комиссия карарлары комиссия утырышында катнашучы әгъзаларның күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәиснең тавышы хәлиткеч булып тора.

Сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсенә түбәндәге белешмәләр керә:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявканың теркәлү номерын, заявканың килү датасын һәм вакытын, юридик затның тулы исемен, юридик зат тарафыннан субсидия күләмен соратып алынган юридик затның адресын күрсәтеп, кергән һәм каралган гаризалар саны;

заявкалары яраклы дип танылган һәм каралган юридик затлар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән юридик затлар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту нигезләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

килешү төзелә торган субсидия алучының исеме һәм аңа бирелә торган субсидиянең күләме.

бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсен урнаштыру сроклары (ул сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак була алмый).

Комиссиянең гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына юридик зат тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

6.4. Әгәр заявка сайлап алуны уздыру турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килсә һәм әгәр заявканы кире кагу өчен нигезләр булмаса, ул дөрес дип таныла.

21. Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итмәү өчен түбәндәгеләр нигез була:

әлеге Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

юридик зат тапшырган заявканың һәм (яки) документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

юридик зат тапшырган заявка составында документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

заявкалар бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң юридик затның заявка бирүе.

22. Министрлык комиссиянең сайлап алу йомгакларын чыгару беркетмәсе нигезендә субсидия бирү турында яисә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул

итә һәм аны сайлап алу йомгакларын чгару беркетмәсенә имза салынган көннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча боерыгы белән раслый.

Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнүе.

6.11. Сайлап алу түбәндәге очракларда уздырылмаган дип таныла:

заявкалар бирү срогы тәмамланган көнгә бер генә заявка да бирелмәгән;

заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча барлык заявкалар кабул ителмәгән.

24. Субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C = P_1 + P_2 + P_3 + P_4,$$

монда:

Р1 - Федераль дәүләт статистикасы хезмәте мәгълүматлары буенча исәпләнә торган Татарстан Республикасында икътисадый эшчәнлекнең тиешле төре буенча айлык уртача хезмәт хакы күләме нигезендә исәпләнә торган, персонал, шул исәптән «Физик-математик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле административ, хезмәте өчен түләүгә чыгымнар һәм салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә хезмәт өчен түләү буенча түләүләр, сум;

$P_2$ – бу Тәртипнең 25 пунктындагы өченче абзацта күрсәтелгән юнәлешләр буенча смета чыгымнары вәкаләтле орган тарафыннан бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган җитештерүче оештыручыларның бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә торган чыгымнар, сум;

Р3 - Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чыгымнарны каплау нормаларыннан чыгып билгеләнә торган «Физик-математик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле командировка чыгымнары;

Р4 - юридик затның өстәмә чыгымнары, шул исәптән гомумхуҗалык һәм гомумҗитештерү чыгымнары, бүлмәләрне арендага алу, канцелярия товарларын сатып алу һәм автоматлаштырылган эш урыннарын оештыру, субсидия суммасының 6 процентыннан артмаган күләмдә.

25. Финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлешләре:

персоналның хезмәте өчен түләү, шул исәптән «Физик-математик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле административ хезмәт өчен түләү һәм салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә хезмәт өчен түләү буенча түләүләр;

физик зат яки шәхси эшмәкәр алар буенча башкаручы булып тора торган «Физик-математик алгары» проекты чараларын оештыруга һәм үткәрүгә бәйле рәвештә заявка бирү һәм (яисә) төзү планлаштыру датасына төзелгән китереп бирү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү шартнамәләре, шул исәптән граждан-хокукый характердагы килешүләр буенча түләү;

«Физик-математик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле командировка чыгымнары;

юридик затның өстәмә чыгымнары, шул исәптән бүлмәләрне арендага алуга, канцелярия товарлары сатып алуга һәм автоматлаштырылган эш урыннарын оештыруга гомумхуҗалык һәм гомумҗитештерү чыгымнары.

26. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

Татарстан Республикасы территориясендә укучылар, ата-аналар (законлы вәкилләр), педагог хезмәткәрләр өчен төрле дәрәҗәдә уздырылган белем бирү һәм башка чаралар саны (муниципаль дәрәҗәдә, төбәк дәрәҗәсендә укыта торган оешмаларда) - кимендә 15, шуларның кимендә 5 муниципаль дәрәҗәдә;

«Физик-математик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында аерым предметларны тирәнтен өйрәнү программаларын һәм (яисә) профориентация чараларын гамәлгә ашыру (пилот физика-математика класслары) мәсьәләсе буенча гомуми белем бирү оешмалары белән үзара хезмәттәшлек турында төзелгән шартнамәләр саны - кимендә 20;

мәгълүмати-методик ярдәм алган «физика», «математика» предметлары буенча педагогик хезмәткәрләр саны - кимендә 90, шул исәптән өстәмә белем бирүнең педагогик хезмәткәрләре - кимендә 70;

индивидуаль эш алып барыла торган яисә «Физик-математик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында ярдәм күрсәтелгән укучылар саны - кимендә 560.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә 2024 елның 31 декабренә кадәр ирешелергә тиеш.

27. Субсидия бирү өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең бертип формасы нигезендә сайлап алу үткәрү йомгаклары беркетмәсен урнаштырган көннең өченче эш көненнән дә соңга калмыйча Министрлык субсидия алучы белән төзи торган килешү нигез була.

Килешүдә Министрлык белән субсидия алучы арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзү шартлары һәм тәртибе булырга тиеш.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) аларга карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет

кодексының 268[1] һәм 269[2] статьялары нигезендә тикшерүгә субсидия алучының ризалыгы;

субсидия алучы, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акчалар алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, акчалар алуны тыю.

Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган бюджет йөкләмәләренең Министрлыкка элек җиткерелгән лимитлары кимегән очракта килешүгә килешүнең яңа шартларын килештергәндә яисә яңа шартлар буенча килештерелмәгәндә килешүне өзү турында шарт кертелә.

28. Кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә субсидия алучы үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Субсидия алучыны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук субсидия алучы бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

29. Субсидия алучы килешү төзүдән баш тарткан очракта, субсидия алучы тарафыннан сайлап алуны уздыру турында игълан ителгән вакытта килешү бирелмәгән очракта, Министрлык заявкасы кими бару тәртибендә юридик заттан соң заявка рейтингында икенче урынга ия булган юридик зат белән килешү төзи.

Сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокуклы затның килешүгә кул куюы тәэмин ителмәгән очракта, субсидия алучы килешү төзүдән читләшкән дип танылала.

30. Министрлык килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган 10 көн эчендә субсидия алучының Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетына субсидия күчерә.

31. Субсидия алучы субсидияләр керү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.

32. Субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше 2025 ел елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы бюджеты keremенә кайтарылырга тиеш.

33. Хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 нче числосына кадәр, шулай ук 2024 елның 30 декабренә кадәр субсидия алучы Министрлыкка субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисап, шулай ук финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра, килешү рәвешендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән рәвешләр буенча бирелә.

Министрлык килгән хисапларны Министрлыкка кергән көннән алып бер эш көне эчендә терки һәм аларны тикшерүне теркәү датасыннан башлап эш көннәрендә исәпләнән торган биш көн эчендә башкара.

34. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

35. Субсидия Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә тулысынча җитмәгән очракта - тулы күләмендә;

субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылган очракта – тулы күләмендә;

субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәсенә ирешү турында хисап, шулай ук финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирелмәгән очракта - тулы күләмендә.

36. Әлеге Тәртипнең 32 һәм 35 пунктларында күрсәтелгән очракларда иректә кире кайтарудан баш тарткан очракта, баш бүлүче, субсидия кире кайтару срогы чыккан көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә, Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрә кайтару буенча чаралар күрә.

37. Субсидияне нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2024 елда дәүләт (муниципаль) учреждениесе булмаган юридик затка «Физик-математик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

Форма

«Физик-математик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан 2024 елда юридик затка субсидия бирүгә сайлап алуда катнашуга заявка

«___»__________ 2024 ел

1. Юридик затның тулы исеме: ________________________________________________
____________________________________________________________________________

2. Юридик затның кыскартылган исеме: __________________________________

3. Төп дәүләт теркәве номеры, салым түләүченең идентификация номеры: _______________________/ _________________________.

4. Юридик затны дәүләт теркәвенә алу датасы: ___________________________

5. Субсидия суммасы: ___________________________________________________

6. Юридик затның урнашкан урыны: ____________________________________

7. Юридик затның почта адресы: ______________________________________

8. Юридик әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен элемтә өчен телефон номеры, электрон почта адресы: __________________________________________.

9. субсидияне күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә счетлар турында мәгълүмат: ___________________________________________

10. Субсидия бирү турында килешүне имзалауга вәкаләтле җитәкче, зат (Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы - булган очракта)__________________________________

Әлеге заявка белән юридик зат Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елда дәүләт (муниципаль) учреждениесе булмаган юридик затка «Физик-математик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 18 ноябрь, 1018 нче карары белән расланган 2024 елда дәүләт (муниципаль) учреждениесе булмаган юридик затка «Физик-математик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый.

Әлеге заявка белән юридик зат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә юридик зат турында, юридик зат тарафыннан бирелә торган заявка турындагы мәгълүматны, субсидия бирү өчен тиешле сайлап алу белән бәйле юридик зат турында башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын раслый.

Кушымталар: 1.
2.

Җитәкче ______________________________ ____________
(Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда) (имза)

_________________________